**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ МИШӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**Өченче чакырылыш**

**Утыз тугызынчы утырыш**

**КАРАРЫ**

2019 ел «19» июнь **№** 115 Олы Мишә авылы

Теләче муниципаль районы Олы Мишә авыл җирлеге Советының «Җирләү эше һәм Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мишә авыл җирлеге территориясендәге муниципаль зиратларны тоту кагыйдәләре турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында «Күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны тормышка ашыру чаралары турында»гы 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»гы 2019 елның 21 маендагы 415 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мишә авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Теләче муниципаль районы Олы Мишә авыл җирлеге Советының 21.11.2016 елның 43 номерлы «Җирләү эше һәм Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мишә авыл җирлеге территориясендәге муниципаль зиратларны тоту кагыйдәләре турында»гы карарына (19.09.2018елның 92 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә :

1) Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мишә авыл җирлеге территориясендә җирләү эшен оештыру тәртибенә:

А) «9. Җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге» бүлегенә:

- 3 пунктны түбәндәге тәртиптә бирергә:

«3. Җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлекчәсе, Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлеге, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты белән килешү буенча җирле үзидарә органы тарафыннан билгеләнә

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Теләче муниципаль районы
Олы Мишә авыл җирлеге башлыгы Г.А.Маннапов